**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

____10.03.2022_______ Балык Бистәсе штп. №____71пг___

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 14 июлендәге “Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау хакында” 162пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләрен һәм хезмәт коллективларын, шулай ук җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне объектив карауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, оештыру-штат чаралары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 14 июлендәге “Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау хакында” 162пг номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау буенча комиссия составын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Р.Җамалиевка йөкләргә.

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2022 елның 10 мартындагы
71пг номерлы карары
белән расланды

**Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Җамалиев Р.Р. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Вафина А.К. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешенү буенча) |
| Шелкова С.А. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы, комиссия сәркатибе (килешенү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Ногманова И.М. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Вафин Ф.М. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Кәримуллина Л.В. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы (килешенү буенча) |
| Шакиров И.З. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт, туризм буенча бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы (килешенү буенча) |
| Галиуллина А.Т. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесенең кадрлар мәсьәләләре буенча әйдәүче белгече (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ситдиков И.М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар буенча консультанты (килешенү буенча) |
| Сәфәрова А.Ф. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге баш белгече (килешенү буенча) |
| Керженцева Г.Ф. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУ директоры (килешенү буенча) |
| Хәмидуллина Н.К. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты аппараты хезмәткәрләренең һөнәр берлеге оешмасы рәисе (килешенү буенча) |